**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**
**ТУКАЙ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ**
**МӘЛӘКӘС ҖИРЛЕГЕ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ**

# КАРАР

«29» январь 2021 ел Мәләкәс авылы № 2

Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы Мәләкәс авыл җирлегендә җирләү буенча хезмәтләрнен гарантияләнгән исемлеге нигезендә күрсәтелә торган хезмәтләрнең бәясен раслау турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ санлы Федераль закон, «Җирләү һәм җирләү эше турында» 1996 елнын 12 гыйнварендәге 8-ФЗ санлы Федераль закон, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 15 статьясы 3 өлеше 15 пункты нигезендә Тукай муниципаль районы Мәләкәс авыл җирлеге Башкарма комитеты

**КАРАР БИРӘ:**

1. 2021 елның 1 февраленнән Тукай муниципаль районы Мәләкәс авыл җирлегендә җирләү буенча хезмәтләрнең гарантияләнгән исемлеге нигезендә күрсәтелә торган хезмәтләрнең бәясен 1 һәм 2 кушымталар нигезендә 6424,98 сум күләмендә билгеләргә һәм гамәлгә кертергә.
2. Әлеге карарны муниципаль районның рәсми сайтында һәм Татарстан Республикасы рәсми хокукый мәгълүмат порталында урнаштырырга.
3. Әлеге карар үтәлешен контрольдә тотуны үз җаваплылыгымда калдырам.

Башкарма комитет Җитәкчесе Ю.П.Васильев

Тукай муниципаль районы Мәләкәс авыл җирлеге Башкарма комитетының 2021 елның 29 январендәге 2 номерлы карарына 1 кушымта

2021 елның 1 февраленнән ТР Тукай муниципаль районы Мәләкәс авыл җирлегендә җирләү буенча хезмәтләрнең бәясе

| **Хезмәт күрсәтү исеме** | **Хезмәт күрсәтү бәясе (сумнарда)** |
| --- | --- |
| 1. Җирләү өчен кирәкле документларны рәсмиләштерү | - |
| 2. Ритуаль билгеләнештәге предметларны бирү һәм китерү | 3012,14 |
| 3. Транспорт хезмәтләре күрсәтү (мәрхүмнең мәетен зиратка алып бару, ритуаль билгеләнештәге предметларны китерү) | 1989,67 |
| 4. Җирләү (кабер казу һәм күмү) | 1423,17 |
| **Барлыгы:** | 6424,98 |